**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең Шыкмай торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

2022 елның 10 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Шыкмай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Түбән Биш авыл җирлеге Шыкмай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт эчендәге Елга аръягы, Урман урам юлларына вак таш җәю;
- урам утларын ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Шыкмай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Түбән Биш авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Биш авыл җирлеге башлыгы Д.В.Насертдинов